# КАРАР
# Татарстан Республикасы Азнакай район Советы

Азнакай шәһәре № 253-35 «22» апрель 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2010 елның 15 декабрендәге «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты органнарын - муниципаль казна учреждениеләрен гамәлгә кую турында» 25-5 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе Нигезләмәсенә үзгәреш кертү хакында

«Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе » МКУ нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2018 елның 1 августында кабул ителгән 10-06/9774 номерлы «Учреждениеләрдә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу чаралары турында»гы хаты нигезендә

Азнакай район Советы **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2010 елның 15 декабрендәге «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты органнарын - муниципаль казна учреждениеләрен гамәлгә кую турында» 25-5 номерлы карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе Нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

дополнить новым разделом 6 следующего содержания:

«6. Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу

6.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы астында учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы аларның хезмәт бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясарга мөмкин һәм учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм хокукларының, шулай ук оешманың законлы мәнфәгатьләре арасында каршылык килеп чыгарга мөмкин.

6.2. Учреждение хезмәткәренең хезмәт бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынуы дигәндә, акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән милек хокуклары, яки үзе өчен яки өченче затлар өчен мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтү рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла.

6.3. Учреждение башлыгы эш бирүчеләргә вазыйфаи бурычларны үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш, ул мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала.

6.4. Учреждение хезмәткәре учреждение җитәкчесенә вазыйфаи бурычларны үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш, ул мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала. Учреждение директорына хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеге, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрләрне теркәү тәртибе учреждение директоры тарафыннан билгеләнә.»;

6, 7 бүлекләрне 7,8 бүлекләр дип санарга.

2. «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» җитәкчесе (Хафизова Г. С.) дәүләт теркәвен үткәрергә һәм гамәлдәге законнар нигезендә Нигезләмәгә үзгәрешләр кертүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http:// aznakyevo.tatarstan.ru. адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Рәис М.З.Шәйдуллин